**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, д.19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 йорт

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**16.03.2020 ел** **№ 7**

**Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында**

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркемгә мөмкин булуын һәм сыйфатын арттыруны тәэмин итү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын расларга.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 25 сентябрендәге 6 нчы номерлы «Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарын.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 мартындагы 34 нче номерлы «Биектау муниципаль районының «Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» карарын;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 19 маендагы 21 нче номерлы «Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 25 августындагы 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5.Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе З.Р.Гарифуллина

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 16 марты № 7 Карары белән

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (алга таба – Регламент) адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәтне алучылар:

1.2.1. күчемсез милек объектына хокукларга ия физик һәм юридик затлар (дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – гариза бирүчеләр).

Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза (алга таба - гариза) адресация объектынының милекчесе тарафыннан үз инициативасы белән яисә адресация объектына түбәндәге хокукларның берсенә ия булган зат тарафыннан бирелә:

а) хуҗалык алып бару хокукы;

б) оператив идарә итү хокукы;

в) гомерлек мирас белән идарә итү хокукы;

г) даими (сроксыз) файдалану хокукы.

1.2.2. Гариза белән гариза бирүченең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәгә нигезләнгән вәкаләтләре нигезендә эш итүче вәкилләре федераль закон күрсәтмәсендә яисә моңа вәкаләтле дәүләт органы яки җирле үзидарә органы актында мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән гариза белән мондый гаризаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән күрсәтелгән милекчеләрнең гомуми җыелышы карары белән бирергә вәкаләтле шундый милекчеләр вәкиле мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәт әгъзалары исеменнән гариза белән мондый ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышы карары

белән кабул ителгән гаризаны бирүгә вәкаләтле ширкәт вәкиле мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге Регламентның 1.2.1 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән зат исеменнән “Кадастр эшчәнлеге турында” Федераль законның 35 статьясында яисә 42.3 статьясында каралган документ нигезендә адреслау объекты булып торучы тиешле күчемсез мөлкәт объектына карата кадастр эшләре яисә комплекслы кадастр эшләре башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: 422723, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 йорт

Эш графигы:

дүшәмбе- җомга:  8.00 дән 17.00 кадәр

шимбә, якшәмбе –ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә өчен телефон (884365) 63-9-51.

Керү шәхесне таныклый торган документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты адресы (алга таба - «Интернет» челтәре): (http://vysokaya-gora.tatar.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук Башкарма комитетның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнашкан муниципаль хезмәт турында белешмәләр урнаштырыла торган мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

2) муниципаль районның рәсми сайтында «Интернет» челтәре ярдәмендә (http:// http:// www. vysokaya-gora.tatar.ru.);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi. tatar.ru/) (алга таба – Региональ портал);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/) (алга таба –Бердәм портал);

5) Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә-шәхсән яки телефон буенча;

язма (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Башкарма комитет белгече тарафыннан Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарында мәгълүмати стендларда урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында һәм муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.5,

2.8, 2.10, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) урнашкан муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

«ТР Электрон хөкүмәте» - Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше системасы, Интернетта адресы: https://intra.tatar.ru.

адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм шул исәптән урам-юл челтәре элементының һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының исемен (кирәк булганда), шулай ук адреслау объектын идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы билгесен үз эченә алган адрес объектының урнашкан урыны тасвирламасы;

дәүләт адреслар реестры - адреслар турында белешмәләрне үз эченә алган дәүләт мәгълүмат ресурсы;

адресация объекты - Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән адресация объектлары исемлегендә каралган капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки башка объект;

федераль мәгълүмат адреслар системасы - дәүләт адреслар реестрын булдыруны, алып баруны һәм куллануны тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«адрес барлыкка китерүче элементлар» - ил, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек, торак пункт, урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы һәм адресация объектының идентификация элементы (элементлары);

«адресация объектының идентификация элементлары» - җир участокларының номерлары, адресациянең башка объектларының типлары һәм номерлары;

«дәүләт адреслар реестрында адресация объекты адресының уникаль номеры» - дәүләт адреслар реестрында адресация объекты адресына бирелә торган язма номеры;

«планлаштыру структурасы элементы» - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе;

«урам-юл челтәре элементы» - урам, проспект, тыкрык, юл, яр буе, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башка.

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының муниципаль районы шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелгән документлардагы белешмәләрнең туры килмәвенә китергән хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яисә арифметик хата я шуңа охшаш хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы күчемсез милек объектларына кагыла, аларга түбәндәгеләр керә: төзелеп беткән капиталь төзелеш объектлары (биналар, төзелеш, корылмалар), төгәлләнмәгән төзелеш объектлары һәм капиталь төзелеш максатларында бирелгән җир кишәрлекләре.

Әлеге Регламентның гамәли көче түбәндәгеләргә кагылмый:

- вак өлешле челтәр объектлары (сәүдә һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсендәге капиталь булмаган стационар һәм стационар булмаган объектлар);

- автомобиль транспорты стоянкалары (күпкатлы стоянкалардан тыш);

- металл һәм аерым торучы капиталь гаражлар (гараж-төзелеш кооперативларыннан тыш);

- югарыда күрсәтелгән объектларны гамәлдәге яисә урнаштырыла торган объектлар өчен бирелгән җир кишәрлекләре.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Адресация объектларына адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару | РФ Шәһәр төзелеше кодексы;<br>РФ Җир кодексы |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органы исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты – (Башкарма комитет) | БК турында Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | 1. Адресация объектына адрес бирү, үзгәртү яисә аның адресын гамәлдән чыгару турындагы карар (2 нче кушымта).<br>2. Адресация объектына адрес бирүдән яисә аның адресын гамәлдән чыгарудан баш тарту турындагы карар (3 нче кушымта) | РФ Хөкүмәте 19.11.2014 №1221 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренең 39 п. |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документларны бирү | Гариза бирү көнен дә кертеп, 10 эш көне дәвамында.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Гаризада (почта яисә электрон адресы буенча) күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә | РФ Хөкүмәте 19.11.2014 №1221 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренең 37 п. |

| | | |
|---|---|---|
| (җибәрү) срогы, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | муниципаль хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәсен җибәрү гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе. | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:<br>- Россия Финанс министрлыгының 11.12.2014 № 146н «Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза, адрес бирүдән яки аның адресын гамәлдән чыгарудан баш тарту турындагы карар формаларын раслау турында» карары нигезендә төзелгән гариза.<br>Гариза бирүче тарафыннан гариза кәгазь чыганакта, салынган документларның исемлеге белән һәм тапшырылуы турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән Башкарма комитетка тапшырыла.<br>Гариза адресация объектының урнашкан урыны буенча башкарма комитетына тапшырыла.<br>Гариза мөрәҗәгать итүченең шәхсән мөрәҗәгатендә яисә мөрәҗәгать итүче вәкилендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхесен яисә мөрәҗәгать итүченең вәкилен раслаучы документ күрсәтелә.<br>Гаризаны мөрәҗәгать итүче вәкиле биргән очракта, мондый гаризаны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә рәсмиләштерелгән мөрәҗәгать итүче вәкиленә бирелгән ышанычнамә беркетелә.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендәге | РФ Хөкүмәте 19.11.2014 №1221 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренең 32 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | Региональ портал аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны гариза бирүчеләр тарафыннан, шул исәптән электрон рәвештә, алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган һәм ведомствоара сорату буенча соратып алына торган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге:<br>а) адресация объектына (объектларына) хокук билгели торган һәм (яисә) хокук раслый торган документлар (күрсәтелгән бина (корылма) яисә корылмага, шул исәптән төзелеше тәмамланмаган, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә аларның төзелеше өчен рөхсәт алу таләп ителми, адрес бирелгән очракта, әлеге бина (төзелеш), корылма урнашкан җир кишәрлегенә хокук билгели һәм (яисә) хокук раслый торган документлар);<br>б) күчемсез милек объектлары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан күчермәләр, аларны үзгәртеп төзүдән адресациянең бер һәм аннан да күбрәк объектын төзү (күчемсез милек объектларын үзгәрткәндә адресациянең бер һәм аннан да күбрәк яңа объектларын барлыкка китергән очракта);<br>в) адресация объектын төзүгә рөхсәт (төзелеп килүче объектларга адрес биргәндә) (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә бинаны (төзелешне), корылманы төзүгә яисә реконструкцияләүгә, төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәсә) һәм (яисә) адресация объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт булган очракта;<br>г) кадастр планында яисә тиешле территориянең кадастр картасында адрес объектының урнашу схемасы (җир | |

| | | |
|---|---|---|
| | кишәрлегенә адрес бирелгән очракта);<br>д) адресация объекты булган күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (кадастр исәбенә куелган адрес объектына адрес бирелгән очракта);<br>е) җирле үзидарә органының торак урынын торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак урынга күчерү турындагы карары (аны торак булмаган бинадан торак булмаган бинага яки торак булмаган бинадан торак бинага күчерү аркасында, мондый адресны үзгәрткән һәм гамәлдән чыгарган очракта, адрес бирелгәндә);<br>ж) адресациянең бер һәм аннан да күбрәк яңа объектларын барлыкка китерүче урынны яңадан төзегәндә һәм (яисә) яңадан планлаштырганда кабул итү комиссиясе акты (күчемсез милек объектларын (биналарны) адресациянең бер һәм аннан да күбрәк яңа объектларын төзү белән үзгәртеп төзегән очракта);<br>з) адресация объекты булган дәүләт кадастр исәбеннән төшерелгән күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә («Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә адресация объекты адресын юкка чыгарган очракта);<br>и) адресация объекты булган күчемсез милек объекты буенча соратыла торган мәгълүматларның Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булмавы турында хәбәрнамә | |

| | | |
|---|---|---|
| | («Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә адресация объекты адресын юкка чыгарган очракта).<br>Әлеге Регламентның 2.6 пунктының 1 абзацындагы "б", "д", "з" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән документлар күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләрне бирүгә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы яки күрсәтелгән орган карары нигезендә аңа буйсынучы федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан вәкаләтле орган соравы буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә эш итүче тарафыннан бирелә.<br>Гариза биргәндә гариза бирүчеләр (мөрәҗәгать итүченең вәкилләре) аңа шушы Регламентның 2.6 пунктындагы 1 абзацының "а", "в", "г", "е", һәм "ж" пунктчаларында күрсәтелгән документларны, әгәр мондый документлар дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яки дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар кулланымында булмаса беркетергә хокуклы.<br><br>(Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 4 сентябрендәге N 1355 карары белән 2020 елның 18 сентябрендә гамәлгә кертелгән редакциядәге абзац. - Алдагы редакцияне кара)<br><br>Вәкаләтле органга электрон документлар рәвешендә | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырыла торган әлеге Регламентның 2.6 пунктындагы "а", "в", "г", "е" һәм "ж" пунктчаларында күрсәтелгән документлар гариза бирүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) электрон имзасы белән таныклана, аның төре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 21.1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә.<br>Гариза бирүченең күрсәтелгән документларны тапшырмавы хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез була алмый.<br>Башкарма комитетка тиешле органнар яисә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүче оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүматның ведомствоара сорату буенча орган яисә оешма тарафыннан тапшырылмавы (үз вакытында бирелмәве) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүчедән таләп итү рөхсәт ителми:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы яисә гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр башкару;<br>- “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар исемлегенә кертелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан | |

| | | |
|---|---|---|
| | Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсынулы оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүмат, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертү турында тапшыру. Гариза бирүче күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда, документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) аларның дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыру, түбәндәге очраклардан тыш,:<br>а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләрен үзгәртү;<br>б) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле һәм элегрәк тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң гариза бирүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү | |

| | | |
|---|---|---|
| | турындагы гаризада һәм документларда хаталар булу;<br>в) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән башта баш тартканнан соң, документларның гамәлдә булу срогы тәмамлану яисә мәгълүматны үзгәртү;<br>г) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән башта баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешма хезмәткәренең ялгыш яисә хокукка каршы гамәле (гамәл кылмавы) документлар белән расланган факты (билгеләре) ачыклану, бу турыда муниципаль хезмәтне күрсәтүче Башкарма комитет җитәкчесенең, күпфункцияле үзәк җитәкчесенең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яки “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма җитәкчесе имзасы белән язмача рәвештә гариза бирүчегә хәбәр итә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенү җиткерелә. | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) тиешле булмаган зат тарафыннан документлар бирү; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) Тапшырылган документларның документлар исемлегенә һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага теркәлә торган документларда алдан әйтелмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатмый торган җитди бозулар бар;<br>4) Документлар тиешле булмаган органга тапшырылу | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>а) адресация объектына адрес бирү турында гариза белән әлеге Регламентның 1.2.1 һәм 1.2.2 дә күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать итте;<br>б) ведомствоара соратуга җавап документның булмавы һәм (яисә) ) адресация объектына адрес бирү яисә аның адресын юкка чыгару өчен кирәкле мәгълүматның булмавы турында сөйли, һәм тиешле документ гариза бирүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тарафыннан үз инициативасы буенча тәкъдим ителмәгән;<br>в) адресация объектына адрес бирү яисә аның адресын гамәлдән чыгару өчен тапшыру йөкләмәсе гариза бирүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) йөкләнгән документлар, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртипне бозып бирелгән;<br>г) 19.11.2014 № 1221 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренең 5, 8 - 11 һәм 14 - 18 пунктларында күрсәтелгән адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару өчен очраклар һәм шартлар юк. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алмыйча күрсәтелә.<br>Орган һәм (яки) вазыйфаи зат, КФҮ һәм (яки) КФҮ хезмәткәре гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән документ бирү нәтиҗәләре буенча бирелгән документка үзгәрешләр кертелгән очракта, гариза бирүчедән түләү алынмый. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү законнар белән каралмаган. | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү законнар белән каралмаган. | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтелгәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратның максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан | Гариза кергән вакыттан бер эш көне эчендә. | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелә торган муниципаль хезмәт һәм хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соратуын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратулар тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре белән һәм һәрбер муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмати стендларга, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән әлеге объектларның инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.<br>Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү максатларында тәэмин ителә:<br>1) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып;<br>2) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;<br>3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен аларның тормыш эшчәнлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| | чикләнүен исәпкә алып, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;<br>4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләр һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;<br>5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>6) махсус укытылуын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Эт-озатучыны махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелүче документ булганда эт-озатучыны кертү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм әлеге пунктның 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган акчалардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге күләме һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашкан; | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату ярдәмендә гариза бирүченең сайлавы (экстерриториаль принцип) буенча җирле үзидарәнең башкарма-күрсәтмә органы органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкин булуы яисә мөмкин булмавы (шул исәптән тулы күләмдә) | кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуда тоткарлыкларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр була:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;<br>4) гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):<br>4.1) муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр башкарыла;<br>4.2) КФҮдә кәгазь чыганакта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта бер тапкыр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә хезмәттәшлеге озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең | |

| | | |
|---|---|---|
| | сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы, терминаль җайланмалар ярдәмендә бәяләргә хокуклы.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталда яисә Республика порталында, КФҮдә алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү гариза бирүченең сайлавы буенча аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча теләсә кайсы КФҮдә гамәлгә ашырыла.<br>Комплекслы сорату составында муниципаль хезмәт күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган | Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:<br>а) Бердәм порталда яисә Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;<br>б) гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән Республика порталының Шәхси кабинетыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон документ рәвешендә гариза бирергә;<br>в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларның үтәлеше турында белешмәләр алырга;<br>г) Республика порталы ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;<br>д) муниципаль хезмәтне электрон документ рәвешендә күрсәтү нәтиҗәсен алырга;<br>е) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язылу (алга таба - язма) Республика порталы, МФЦ контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.<br>Гариза бирүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш вакытка күпфункцияле кабул итү графигының үзәгендә билгеләнгән чикләрдә язылу мөмкинлеге бирелә.<br>Билгеләнгән датага язылу бу дата башланганчы бер тәүлек кала тәмамлана.<br>Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен гариза бирүчегә система тарафыннан соратылган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:<br>фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда);<br>телефон номерын;<br>электрон почта адресы (теләк буенча);<br>кабул итү өчен теләгән датаны һәм вакытны.<br>Мөрәҗәгать итүче алдан язылганда хәбәр иткән белешмәләр туры килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүче шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документларга алдан язылу юкка чыгарыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Алдан язылуны башкарганда, гариза бирүчегә талон-раслау бастырып алу мөмкинлеге тәэмин ителә. Әгәр гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска шулай ук, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.<br>Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри тәртиптә, алдан язылу кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан соң 15 минут үткәннән соң килмәгән очракта юкка чыгарылуы хәбәр ителә.<br>Мөрәҗәгать итүче алдан язылудан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.<br>Гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул итү максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәкле вакыт интервалының озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүдән тыш башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр күрсәтү

3.2.1. Гариза бирүче Башкарма комитетка шәхсән үзе, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет белгече гариза бирүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителә торган документациянең составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) кәгазь чыганакта, салынган документларның исемлеге белән һәм тапшырылуы турында хәбәрнамә белән почта аша яисә шәхсән үзе, яисә электрон документ рәвешендә яисә КФҮ аша, муниципаль хезмәт күрсәтү турында КФҮнең читтәге эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза җибәрә һәм документларны әлеге Регламентның 2.6 пункты нигезендә Башкарма комитетка тапшыра.

Гариза электрон формада алынганда, гаризалар кабул итүгә җаваплы Башкарма комитетның вазыйфаи заты:

а) электрон документлар әйләнеше системасында гаризаны теркәүне тәэмин итә, шул ук вакытта гаризаны «Ведомство тарафыннан кабул ителгән» яки «Эшкәртүдә» статусы бирелә, бу Региональ порталның «Шәхси кабинетында» чагылдырыла;

б) Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон имзаның дөреслек шартлары үтәлешен тикшерә (мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән

квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган очракта).

Әгәр көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның дөреслеге шартларын үтәмәү ачыкланмаган булса, Башкарма комитетның вазыйфаи заты гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән, гариза Башкарма комитетка кергәннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, гаризаның керүче теркәлү номерын, гаризаны алу датасын, аңа тапшырылган документларның исемнәре исемлеген, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасын үз эченә алган гаризаның килүе турында хәбәрнамәне җибәрә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның дөреслеге шартларын үтәмәү ачыкланган очракта, Башкарма комитетның вазыйфаи заты:

электрон рәвештә кергән документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә;

мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен нигез булып торган 06.04.2011 № 63-ФЗ "Электрон имза турында" Федераль законның 11 статьясы пунктларын күрсәтеп, электрон формада кабул ителгән карар турында хәбәрнамә җибәрә. Мондый хәбәрнамә Башкарма комитетның вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.08.2012 № 852 карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны куллану кагыйдәләренең 9 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән җибәрелә.

3.3.2. Гаризаларны кабул итүче Башкарма комитет белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклау;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә белән эш йөртелсә);

әлеге Регламентның 2.6 пунктына туры килгән документларның булуын тикшерү;

документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документ күчермәләрен тиешенчә эшләү, документларда бозулар, өстәүләр, сызылган сүзләр, һәм башка алдан кисәтелмәгән төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, Башкарма комитет белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

гариза бирүчегә тапшырылган документларның исемлеге күчермәсен документларны кабул итү датасы турында тамга белән, бирелгән керүче номерны, анда муниципаль хезмәт күрсәтү датасын һәм вакытын күрсәтеп бирү;

гаризаны Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документларны кабул итүгә каршылыклар булган очракта, документларны кабул итүче Башкарма комитет белгече гариза бирүчене гаризаны теркәүгә каршылыклар булуы турында кисәтә һәм, язма формада кабул итүгә каршы булуның сәбәпләрен аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гариза һәм документларны кабул итү вакыты - 15 минут;
гаризаны теркәү гариза тапшыру моментыннан бер эш көне эчендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Башкарма комитетка җибәрә.

Гариза бирүче нәтиҗәне электрон рәвештә алу ысулын сайлаганда, мөрәҗәгать итүчегә электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Башкарма комитет белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада бирү турындагы соратулар җибәрә:

1) күчемсез милек объектлары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан күчермәләр, аларны үзгәртеп төзү нәтиҗәсендә адресациянең бер һәм аннан да күбрәк объектын төзү (күчемсез милек объектларын үзгәрткәндә адресациянең бер һәм аннан да күбрәк яңа объектларын барлыкка китергән очракта);

2) адресация объекты булган күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (кадастр исәбенә куелган адрес объектына адрес бирелгән очракта);

3) адресация объекты булган дәүләт кадастр исәбеннән төшерелгән күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә адресация объекты адресын гамәлдән чыгарган очракта);

4) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында адресация объекты булып торучы күчемсез мөлкәт объекты буенча соратыла торган белешмәләр булмау турында хәбәрнамә (әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә адреслау объекты адресын юкка чыгарган очракта).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләре соратып алына торган документлар (мәгълүмат) тапшыралар яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында хәбәрнамәләр җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәге срокларда тормышка ашырылалар:

Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча, өч эш көненнән дә артмаган вакытта;

башка тәэмин итүчеләр буенча – әгәр дә ведомствоара сорату әзерләү һәм ведомствоара таләпкә җавап җибәрүнең федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирүче оешмага кергән көннән биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Башкарма комитет белгече гамәлгә ашыра:

гаризага кушымта итеп биреленүче документлардагы белешмәләрне тикшерү;

әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Башкарма комитет белгече баш тарту турында карар проектын әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Башкарма комитет белгече гамәлгә ашыра:

- ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» РДУП №_______ (алга таба «ТИБ» РДУП) ________МРФ бирелгән адреслар булуы турында сорату әзерләү;

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар соратуларга җаваплар кергән вакыттан соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән адреслар турында «ТИБ» РДУП нә сорату;

3.5.2. «ТИБ» РДУП белгече соратуда күрсәтелгән адресны тикшерә һәм бирелгән адреслар турында белешмә әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар «ТИБ» РДУП регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән адреслар турында белешмә.

3.5.3. Башкарма комитет белгече, «ТИБ» РДУПтан җавап алганнан соң, гамәлгә ашыра:

адресация объектына адрес бирү, үзгәртү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын рәсмиләштерү;

документ проектын Башкарма комитет җитәкчесе белән килештерү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар «ТИБ» РДУПтан җавап алу мизгеленнән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә килештерүгә юнәлдерелгән документ проекты.

3.5.4. Башкарма комитет җитәкчесе, карар проектына яки баш тарту турындагы карар проектына кул куя һәм Башкарма комитет белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: адресация объектына адрес бирү, үзгәртү турында имзаланган карар яисә кире кагу турында карар.

3.5.5. Башкарма комитет белгече адресация объектына адрес бирү, үзгәртү яки кире кагу турындагы карарны терки, номер тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: адресны бирү, үзгәртү турында теркәлгән карар яисә баш тарту турында карар.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе бирү

3.6.1. Башкарма комитет белгече, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм мөрәҗәгать итүчегә йә почта аша адрес объектына бирү, адресын үзгәртү яисә кире кагу турында карарны җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

15 минут дәвамында – гариза бирүче шәхсән килгән очракта;

почта аша җавап җибәрелгән очракта әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедура тәмамланган вакыттан алып бер эш көне дәвамында.

Процедураның нәтиҗәсе: адресация объектына адрес бирү, аны үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (юнәлдерелгән) карар яисә кире кагу турында карар.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия булган, техник хата булуны раслаучы документлар.

Техник хатаны төзәтү турында гариза муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә гариза бирүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Республика порталы яисә МФЦ аша тапшырыла.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

